| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ТУКТАРОВО-УРДАЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ТУКТАР-УРДАЛАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 3 нче сентябре № 13

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 26 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган 2021 һәм аннан соңгы елларга Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә (06.03.2024 № 3 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 26 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган 2021 һәм аннан соңгы елларга Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә (06.03.2024 № 3 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 12 пункттан түбәндәге эчтәлекле абзацны төшереп калдырырга:

«Салым чыгымнары кураторы тарафыннан бирелгән ташламаларның түләүчеләр тарафыннан таләп ителүен бәяләүне уздыру максатларында әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән ташлама таләп ителмәгән дип танылa торган чагыштырманың минималь күрсәткече билгеләнергә мөмкин.»;

2) 15.1 пунктны төшереп калдырырга;

3) 16.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16.1. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль берәмлекнең техник салым чыгымнарына карата үткәрелми.».

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Туктар-Урдаласы авылы, Туктар-Урдаласы

авылы, Совет ур., 98 й., мәдәният йорты бинасында Совет ур., 103 й., Карагай авылы КФҮ бинасында Тельман ур., 31 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Туктар-Урдаласы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Г.Ә.Әхмәтова